# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**30 ноябрь, 2021 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 21 нчы ноябрендә 13 сәг 00 минутта , 2021 елның 23 нчы ноябрендә 7 сәг 00 минутта, 2021 елның 25 нче ноябрендә 13 сәг 00 минутта, 2021 елның 27 нче ноябрендә 13 сәг 00 минутта, 2021 елның 28 нчы ноябрендә 17 сәг 00 минутта, 2021 елның 30 нче ноябрендә 07 сәг 00 минутта булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- җирлек территориясен төзеклəндерүне оештыру:
- җәйге чорда территорияне чабу
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү
- зиратны чистарту һәм зираттан чүп-чар чыгару
- Федоровский җирлек торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларны норматив хәлгә китерү ;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту
- урам яктырткычларын ремонтлау һәм материаллар сатып алу
- торак пунктның янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен сулыкны кисү буенча эшләрне гамәлгә ашыру

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланырга рөхсәт итәргә.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 478 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -258, бу 54 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 249 катнашучы тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенның 9 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- җәйге чорда территорияне чабу
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү
- зиратны чистарту һәм зираттан чүп-чар чыгару
-Федоровский җирлек торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларны норматив хәлгә китерү ;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту
- урам яктырткычларын ремонтлау һәм материаллар сатып алу
- торак пунктның янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен сулыкны кисү буенча эшләрне гамәлгә ашыру.

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланырга рөхсәт итәргә.»

3. Әлеге карарны мәгъүлүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгъүлүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Федоровский авыл җирлеге Башлыгы — Ф.Ф.Зәйнуллин